# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында"
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 16 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында" 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 18 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4 статья. **Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасының составы**

1. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләрдән һәм түбәндәге өлкәләргә караган региональ әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру карталарыннан гыйбарәт:

1) транспорт (тимер юл, су, һава транспорты), региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары;

2) муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны, эпидемияләрне кисәтү һәм алардан килгән зыяннарны бетерү;

3) мәгариф;

4) сәламәтлек саклау;

5) физик культура һәм спорт;

6) Татарстан Республикасы вәкаләтләре нигезендә башка өлкәләр.

2. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасындагы территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләрдә урнаштыру өчен планлаштырыла торган региональ әһәмияттәге объектларның төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары, урнашу урыны (муниципаль район, җирлек, шәһәр округы, торак пункт исемнәре күрсәтелә), шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә, күрсәтелә.

3. Региональ әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру карталарында урнаштыру өчен планлаштырыла торган региональ әһәмияттәге объектлар чагылдырыла.

4. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасына аны нигезләү материаллары текст һәм карталар рәвешендә кушымта итеп бирелә.";

2) 5 статьяда:

а) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасын алып бару тәртибе үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән Интернет челтәрендәге рәсми сайттан файдаланып, территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проектыннан һәм мондый проектны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген аны расларга кимендә өч айдан да соңга калмыйча тәэмин итәргә тиеш.";

в) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

"$6^1$. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 16 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проектыннан һәм мондый проектны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында шушы файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән көннән алып өч көн эчендә электрон рәвештә һәм (яисә) почта аша хәбәр итә.";

г) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, Интернет челтәрендәге рәсми сайттан файдаланып, территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасын территориаль планлаштыруның расланган схемасыннан һәм аны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген Татарстан

Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслаган көннән алып 10 көннән артмаган вакыт эчендә тәэмин итә.";

д) түбәндәге эчтәлекле 11 өлеш өстәргә:

"11. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү әлеге статьяда һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9 һәм 16 статьяларында каралган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.";

3) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6 статья. **Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасының составы**

1. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәдән;

2) муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасыннан.

2. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасындагы территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәгә муниципаль районның урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларының төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турындагы белешмәләр, аларның төп характеристикалары, урнашу урыны (җирлек, торак пункт исемнәре күрсәтелә), шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә, керә.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән картада муниципаль районның түбәндәге өлкәләргә караган урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектлары чагылдырыла:

а) җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итү;

б) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юллары;

в) мәгариф;

г) сәламәтлек саклау;

д) физик культура һәм массакүләм спорт;

е) көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм яңадан эшкәртү;

ж) муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка өлкәләр.

4. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасына аны нигезләү материаллары текст һәм карталар рәвешендә кушымта итеп бирелә.";

4) 7 статьяда:

а) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7. Муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы, Интернет челтәрендәге рәсми сайттан файдаланып, территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы проектыннан һәм мондый проектны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген аны расларга кимендә өч айдан да соңга калмыйча тәэмин итәргә тиеш.";

г) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11. Муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 21 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы проектыннан һәм мондый проектны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында шушы файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән көннән алып өч көн эчендә электрон рәвештә һәм (яисә) почта аша хәбәр итә.";

д) түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 өлешләр өстәргә:

"12. Муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы, Интернет челтәрендәге рәсми сайттан файдаланып, территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы муниципаль районны территориаль планлаштыруның расланган схемасыннан һәм аны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын раслаган көннән алып 10 көннән дә артмаган вакыт эчендә тәэмин итә.

13. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү әлеге статьяда һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9 һәм 21 статьяларында каралган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.";

5) 8 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирлекнең генераль планы, шәһәр округының генераль планы составы**

1. Җирлекнең генераль планы, шәһәр округының генераль планы (алга таба – генераль план) түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәдән;

2) җирлекнең яисә шәһәр округының җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасыннан;

3) җирлек яисә шәһәр округы составына керә торган торак пунктларның чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктларның чикләре) картасыннан;

4) җирлекнең яисә шәһәр округының функциональ зоналары картасыннан.

2. Генераль пландагы территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәгә түбәндәгеләр керә:

1) җирлекнең, шәһәр округының урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларының төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турындагы белешмәләр, аларның төп характеристикалары, урнашу урыны (линия объектлары

булмаган җирле әһәмияттәге объектлар өчен функциональ зоналар күрсәтелә), шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә;

2) функциональ зоналарның параметрлары, шулай ук, линия объектларыннан тыш, аларда урнаштыру өчен планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектлар, региональ әһәмияттәге объектлар, җирле әһәмияттәге объектлар турында белешмәләр.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 – 4 пунктларында күрсәтелгән карталарда тәңгәл рәвештә түбәндәгеләр чагылдырыла:

1) җирлекнең, шәһәр округының түбәндәге өлкәләргә карый торган урнаштыру өчен планлаштырылучы җирле әһәмияттәге объектлары:

а) халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су җибәреп тору;

б) җирле әһәмияттәге автомобиль юллары;

в) шәһәр округының генераль планын әзерләгән очракта, физик культура һәм массакүләм спорт, мәгариф, сәламәтлек саклау, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм яңадан эшкәртү;

г) җирлекнең, шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка өлкәләр;

2) җирлек яисә шәһәр округы составына керә торган торак пунктларның чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктларның чикләре);

3) үзләрендә урнаштыру өчен планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны (линия объектларыннан тыш) һәм федераль әһәмияттәге линия объектларының, региональ әһәмияттәге линия объектларының, җирле әһәмияттәге линия объектларының урнашу урынын күрсәтеп, функциональ зоналарның чикләре һәм тасвирламасы.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 – 4 пунктларында күрсәтелгән һәм генераль план составына керә торган карталар, генераль планның гамәли көче кагыла торган территориянең мәйданын һәм халык санын (гамәлдәге һәм фаразлана торган) исәпкә алып, генераль план проектын әзерләү биремендә билгеләнә торган түбәндәге масштабларда әзерләнә:

1) 1:25000 – 1:10000 масштабы – халык саны 500 мең һәм аннан да күбрәк кеше булганда;

2) 1:10000 – 1:5000 масштабы – халык саны 100 мең кешедән алып 500 мең кешегә кадәр булганда;

3) 1:5000 масштабы – халык саны 100 мең кешедән әзрәк булганда.

5. Генераль планга аны нигезләү материаллары текст һәм карталар рәвешендә кушымта итеп бирелә.";

7) 10 статьяда:

а) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. **Генераль планны әзерләү һәм генераль планга үзгәрешләр кертү тәртибе**";

б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

г) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8. Җирлекнең, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органы, Интернет челтәрендәге рәсми сайттан файдаланып, территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы генераль план проектыннан һәм мондый проектны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген аларны расларга кимендә өч айдан да соңга калмыйча тәэмин итәргә тиеш.";

д) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11. Җирлекнең, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы генераль план проектыннан һәм мондый проектны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында шушы файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән көннән алып өч көн эчендә электрон рәвештә һәм (яисә) почта аша хәбәр итә.";

е) түбәндәге эчтәлекле 14 һәм 15 өлешләр өстәргә:

"14. Җирлекнең, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органы, Интернет челтәрендәге рәсми сайттан файдаланып, территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы расланган генераль планнан һәм генераль планны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген генераль планны раслаган көннән алып 10 көннән дә артмаган вакыт эчендә тәэмин итә.

15. Генераль планга үзгәрешләр кертү әлеге статья һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9 һәм 25 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.";

8) 11 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 14 статьяда:

а) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

"$3^1$. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары проекты аны расларга кимендә ике айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.";

в) 4 өлешнең 2 пунктындагы "дәүләт төзелеше" сүзләрен "региональ дәүләт төзелеше" сүзләренә алмаштырырга, "территориаль планлаштыру документларының проектларына," сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып раслый. Республика нормативларын раслау турындагы карар кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми серверында урнаштырыла.";

10) 15 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"15 статья. **Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе составына карата таләпләр**";

11) 16 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16 статья. **Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеге тәртибенә карата таләпләр**";

12) 17 статьяда:

а) 2 өлештә:

1 пунктта:

"б" пунктчасында "объектларын" сүзеннән соң ", гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе сызыкларына үтеп керү юлларын" сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле "г" пунктчасын өстәргә:

"г) федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру зоналарының чикләре;";

2 пунктта "республика" сүзен "региональ" сүзенә алмаштырырга;

б) 4 өлешнең 3 пунктында "урамнар-юллар челтәрен" сүзләре алдыннан "парковкаларны (парковкалау урыннарын) урнаштыру схемасын үз эченә алырлык" сүзләрен өстәргә;

13) 18 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

"$4^1$. Территорияне планлаштыру документациясе, ул расланганчы, территорияләренә карата шундый документация эшләнгән җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органнары белән әлеге статьяның 4 өлешендә каралган срокларда килештерелергә тиеш.";

б) 5 өлешнең 3 пунктындагы "техник регламентлар," сүзләреннән соң "шәһәр төзелешен проектлау нормативлары," сүзләрен өстәргә;

14) 19 статьяда:

а) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"19 статья. **Региональ әһәмияттәге объектлар**";

б) беренче абзацта "Республика әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектларына" сүзләрен "Региональ әһәмияттәге объектларга" сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта "транспорт" сүзеннән соң "(тимер юл, су, һава транспорты)" сүзләрен өстәргә;

г) түбәндәге эчтәлекле 8 – 12 пунктлар өстәргә:

"8) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары;

9) Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф объектлары;

10) региональ әһәмияттәге сәламәтлек саклау объектлары;

11) региональ әһәмияттәге физик культура һәм спорт объектлары;

12) федераль яисә республика программалары нигезендә урнаштырыла торган агросәнәгать комплексы объектлары.";

15) түбәндәге эчтәлекле $19^1 - 19^3$ статьялар өстәргә:

"$19^1$ статья. **Муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектлары**

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль районнар уставлары нигезендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә муниципаль районнарың җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм муниципаль районнарны социаль-икътисадый үстерүгә шактый йогынты ясый торган капиталь төзелеш объектлары, башка объектлар, территорияләр, шул исәптән түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль район составына керә торган җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итү объектлары;

2) муниципаль район чикләрендәге торак пунктларның чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юллары;

3) муниципаль район чикләрендәге җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен кирәкле транспорт объектлары;

4) муниципаль район территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итә торган объектлар;

5) мәгариф объектлары;

6) муниципаль район территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә торган сәламәтлек саклау объектлары;

7) көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм яңадан эшкәртү объектлары;

8) мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектлары;

9) җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектлары;

10) мәдәният объектлары һәм буш вакытны уздыру оешмалары;

11) муниципаль район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар объектлары;

12) муниципаль районны икътисадый һәм социаль үстерү бурычларын хәл итү өчен максатчан программаларда каралган җитештерү, шул исәптән сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы, билгеләнешендәге объектлар;

13) физик культура һәм массакүләм спорт объектлары;

14) халыкны социаль тәэмин итү һәм социаль яклау объектлары;

15) гражданнар оборонасы, муниципаль район халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектлар;

16) муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка объектлар.

19[2] статья. **Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектлары**

Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, җирлекләр уставлары нигезендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм җирлекләрне социаль-икътисадый үстерүгә шактый йогынты ясый торган капиталь төзелеш объектлары, башка объектлар, территорияләр, шул исәптән түбәндәгеләр керә:

1) халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су җибәреп тору объектлары;

2) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары;

3) социаль яклауга һәм ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның торак хокукларын тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган торак төзелеше объектлары;

4) җирлек чикләрендәге халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен кирәкле транспорт объектлары;

5) мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектлары;

6) җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектлары;

7) мәдәнrealизация, массакүләм ял итү объектлары һәм буш вакытны уздыру оешмалары;

8) физик культура һәм массакүләм спорт объектлары;

9) көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару объектлары;

10) җирлек территориясен төзекләндерү, яшелләндерү объектлары;

11) җирлектә ритуаль хезмәтләр күрсәтү объектлары;

12) гражданнар оборонасы, җирлек халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектлар;

13) җирлек территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар объектлары;

14) җирлекне икътисадый һәм социаль үстерү бурычларын хәл итү өчен максатчан программаларда каралган җитештерү, шул исәптән авыл хуҗалыгы, билгеләнешендәге объектлар;

15) халыкны социаль тәэмин итү һәм социаль яклау объектлары;

16) җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка объектлар.

## 19$^{3}$ статья. **Шәһәр округының җирле әһәмияттәге объектлары**

Шәһәр округының җирле әһәмияттәге объектларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, шәһәр округлары уставлары нигезендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм шәһәр округларын социаль-икътисадый үстерүгә шактый йогынты ясый торган капиталь төзелеш объектлары, башка объектлар, территорияләр, шул исәптән түбәндәгеләр керә:

1) халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су җибәреп тору объектлары;

2) шәһәр округлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары;

3) социаль яклауга һәм ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның торак хокукларын тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган торак төзелеше объектлары;

4) шәһәр округы чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен кирәкле транспорт объектлары;

5) шәһәр округы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итә торган объектлар;

6) мәгариф учреждениеләре;

7) шәһәр округы территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә торган сәламәтлек саклау учреждениеләре;

8) мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектлары;

9) җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектлары;

10) мәдәният, массакүләм ял итү объектлары һәм буш вакытны уздыру оешмалары;

11) физик культура һәм массакүләм спорт объектлары;

12) көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын җыю, чыгару, утильләштерү һәм яңадан эшкәртү объектлары;

13) шәһәр округы территориясен төзекләндерү, яшелләндерү объектлары;

14) шәһәр округында ритуаль хезмәтләр күрсәтү объектлары;

15) гражданнар оборонасы, шәһәр округы халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектлар;

16) шәһәр округы территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар объектлары;

17) шәһәр округын икътисадый һәм социаль үстерү бурычларын хәл итү өчен максатчан программаларда каралган җитештерү, шул исәптән сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы, билгеләнешендәге объектлар;

18) халыкны социаль тәэмин итү һәм социаль яклау объектлары;

19) шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка объектлар.";

16) 20 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 10 марты
№ 17-ТРЗ